**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1021**
**16.02.2023**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен бәя нормативы турында

Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Законын, Татарстан Республикасының «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Законын тормышка ашыруны тәэмин итү максатында, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «2023 елның беренче ярты еллыгына Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен бәя нормативы һәм 2023 елның I кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 2022 елның 22 декабрендәге 1111/пр номерлы Приказы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килүче керемнең чик күрсәткечен һәм керемнең максималь күләмен исәпләү өчен Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен бәя нормативын 2023 елның беренче ярты еллыгына 74 312 сум күләмендә билгеләргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары А.С. Ганиевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов